ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 481-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе                                                  Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 19 октябре
№ 2172-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (II өлеш); 2005, № 2, № 4 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 11; 2006, № 4, № 7 (I өлеш); 2007, № 7 (I өлеш), № 8; 2008, № 1; 2009, № 1, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 3, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3, № 7, № 12 (I өлеш); 2014, № 5, № 11 (VI өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2016, № 3, № 5, № 6 (I өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 36 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш), № 24 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 41 пункт өстәргә:
«41) җирлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

2) 16 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 36 пункт өстәргә:
«36) муниципаль район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

3) 17 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 45 пункт өстәргә:
«45) шәһәр округы милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны гамәлгә ашыру һәм мондый зыянны бетерүне оештыру.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

Закон проекты «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының аерым нигезләмәләрен федераль законнардагы үзгәрешләргә туры китерүгә юнәлдерелгән.

«Россия Федерациясенең аерым закон акларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 августындагы 449-ФЗ номерлы Федераль закон белән шәһәр җирлекләренең, муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә тиешле муниципаль берәмлек милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территориягә карата әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне оештыру кертелгән.

Әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм мондый зыянны бетерүне оештыру Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырылачак.

Шуңа бәйле рәвештә закон проектында «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15, 16 һәм 17 статьяларына төгәлләштерә торган үзгәрешләр кертү каралган.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнары актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.